ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 45 һәм 76 статьяларына һәм «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2020 елның 12 мартында
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Гаилә кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 9 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 5, № 7; 2014, № 4, № 6 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 60 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 45 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ өлеш өстәргә:

«$2^1$. Бер гаиләдә яшәүче һәм тору урыннары уртак булган балалар абыйлары һәм (яисә) апалары укый торган дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмаларына мәктәпкәчә белемнең һәм башлангыч гомуми белемнең төп гомуми белем бирү программалары буенча белем алырга өстенлекле кабул ителү хокукына ия.»;

б) 3 өлештә «тәрбияләнү,» сүзеннән соң «белем алу,» сүзләрен өстәргә;

2) 76 статьяның 1 өлешендә «(балигъ булмаган балалар яисә хезмәткә сәләтсез ярдәмгә мохтаҗ балигъ булган балалар каты авырганда, гарипләнгәндә, аларны даими карап торган өчен түләргә кирәк булганда һәм башка очракларда)» сүзләрен «(балигъ булмаган балалар яисә хезмәткә сәләтсез ярдәмгә мохтаҗ балигъ булган балалар каты авырганда, гарипләнгәндә, аларны карап торган өчен түләргә кирәк булганда, даими яшәү өчен яраклы торак урын булмаганда һәм башка очракларда)» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

«Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7; 2014, № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 3 (I өлеш), № 40 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 2 өлешендә:

а) түбәндәге эчтәлекле $5^1$ пункт өстәргә:

«$5^1$) Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган методик тәкъдимнәрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы мәктәпкәчә белемнең һәркем өчен мөмкин булуының мәгълүмат системасын булдыру һәм алып бару, шул исәптән әлеге мәгълүмат системасыннан балаларның ата-анасына (законлы вәкилләренә) белешмәләр бирү тәртибен урнаштыру, шулай ук күрсәтелгән мәгълүмат системасының заказчыларын һәм операторларын билгеләү;»;

б) 10 пунктта «тәкъдим ителгән» сүзләрен «рөхсәт ителгән» сүзләренә алмаштырырга;

2) 4 статьяның 2 өлешендәге $13^1$ пунктында «гамәлгә ашыручы оешмаларның белем бирү эшчәнлеге шартлары» сүзләрен «гамәлгә ашыра торган оешмалар тарафыннан белем бирү эшчәнлеген башкару шартлары» сүзләренә алмаштырырга;

3) 14 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ өлеш өстәргә:

«$2^1$. Бер гаиләдә яшәүче һәм тору урыннары уртак булган балалар абыйлары һәм (яисә) апалары укый торган дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмаларына мәктәпкәчә белемнең һәм башлангыч гомуми белемнең төп гомуми белем бирү программалары буенча белем алырга өстенлекле кабул ителү хокукына ия.»;

б) түбәндәге эчтәлекле 7 өлеш өстәргә:

«7. Мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыра торган дәүләт яисә муниципаль мәгариф оешмаларына мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программалары буенча укырга кабул итү, әлеге Законның 17 статьясындагы 4 өлешендә күрсәтелгән Татарстан Республикасы мәктәпкәчә белемнең һәркем өчен мөмкин булуының мәгълүмат системасыннан файдалану юлы белән, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыра торган органы яисә мәгариф өлкәсендә идарәне гамәлгә ашыра торган җирле үзидарә органы юлламасы буенча гамәлгә ашырыла.»;

4) 16 статьяның 3 өлешендә «һәм аның нәтиҗәләре үзгәрү динамикасын,» сүзләреннән соң «шул исәптән белемнең сыйфатын бәяләү кысаларында,» сүзләрен өстәргә;

5) 17 статьяга түбәндәге эчтәлекле 4 һәм 5 өлешләр өстәргә:

«4. Һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем бирүне, балаларны карап торуны һәм карауны оештыру, балаларның ата-аналарына (законлы вәкилләренә) дәүләт яисә муниципаль мәгариф оешмаларында урыннар бирүнең чиратлылыгы турында һәм урыннар бирүнең чиратлылыгы үзгәрү нигезләре хакында мәгълүмат бирүне тәэмин итү максатларында, мәктәпкәчә белемнең һәркем өчен мөмкин булуы, балаларны карау һәм карап тору турында мәгълүматны үз эченә алган Татарстан Республикасы мәктәпкәчә белемнең һәркем өчен мөмкин булуының мәгълүмат системасыннан файдаланыла.

5. Татарстан Республикасы мәктәпкәчә белемнең һәркем өчен мөмкин булуының мәгълүмат системасын булдыру һәм аны алып бару, шул исәптән әлеге мәгълүмат системасыннан балаларның ата-аналарына (законлы вәкилләренә) белешмәләр бирү Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

6) 18 статьяның 2 өлешенә «белем бирү рәвешләрен,» сүзләреннән соң «укучыларны практик әзерләүне дә кертеп,» сүзләрен өстәргә.

**3 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 2 статьясындагы 4 һәм 6 пунктларыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 2 статьясындагы 4 һәм 6 пунктлары 2020 елның 1 июленнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2020 ел, 28 март
№ 13-ТРЗ